# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Шәмә авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шәмә авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Шәмә авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
   - Широкая урамында авыл эчендәге юл төзелеше;
   - җәйге чорда грейдерлау һәм территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
   - кышкы чорда җирлек эчендәге юлларны чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
   - урам утларын карап тоту (лампаларны ремонтлау, сатып алу);
   - суүткәргечне карап тоту;
   - зур күләмле чүпләрне җыю,чыгару (айга бер тапкыр ) .

   Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Биләр авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.
2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Биләр авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Биләр авыл җирлеге башлыгы Рузәнов А.И.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БИЛЯРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
СОВЕТ БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ